**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Советы Карары**

**22 апрель 2019 ел** **№ 107**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге җирле үзидарә органының законга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге җирле үзидарә органының Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге җирле үзидарә органы тарафыннан кабул ителгән (чыгарылган) муниципаль норматив хокукый актларга һәм законнарга үзгәрешләр кертү буенча эшчәнлеген камилләштерү максатларында, «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карар чыгарды :

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге җирле үзидарә органының законга һәм муниципаль норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү мониторингын үткәрү турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге җирле үзидарә органы:

үз нормалар ижат итү эшчәнлегендә әлеге карарның 1 пункты белән расланган Нигезләмәгә таянып эш итәргә;

күрсәтелгән Нигезләмәнең үтәлеше өчен җаваплы затларны билгеләү;

җаваплы затлар тарафыннан билгеләнгән муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи

күрсәтмәләренә тиешле үзгәрешләр кертергә.

3.Әлеге карарны мәгълүмат стендларында , Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб –адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында : pravo.tatarstan.ru веб –адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән ун көн узгач үз көченә керә.

Әтнәмуниципаль районы
Олы Әтнә авыл башлыгы Г.Г.Хакимов